КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 июнь г.Казань № 438

Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен расларга

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 8 июнь, 438 нче карары белән расланды

Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында гомуми таләпләр хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасында балаларга табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә өстәмә белем бирү чараларын оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба - субсидияләр, коммерциягә карамаган оешмалар).

2. Субсидияләр гамәлгә куючысы (гамәлгә куючыларының берсе) Татарстан Республикасы булган, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, төп максаты - «Балаларга өстәмә белем бирү системасының яңа моделе» стратегик инициативасын гамәлгә ашыру булган коммерциягә карамаган оешмаларга табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү чараларын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен бирелә, шул исәптән:

табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә гомуми белем бирү программаларының һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә торган шартлар тудыру;

педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

балаларны федераль һәм төбәкара дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуга әзерләү, шул исәптән конкурсның төбәк этапларын уздыру;

укучыларның проект эшчәнлеге өчен реаль технологик бурычларны (шул исәптән сәнәгать предприятиеләре катнашында) хәл итүгә юнәлдерелгән өстәмә гомуми белем бирү программаларын эшләү;

бер мәсьәләне бергәләп хәл итү белән даими нигездә шөгыльләнүче өч кешедән ким булмаган гомуми белем бирү оешмаларында укучылар төркемнәренә ярдәм итү, шулай ук аларның инженерлык ярышларында катнашуларын тәэмин итү;

хакатоннар (төрле өлкәләрдәге программа белән тәэмин итү белгечләре (программистлар, дизайнерлар, менеджерлар) нинди дә булса проблеманы хәл итү өстендә бергә эшләгән чаралар) үткәрү;

балаларның проект эшчәнлеге буенча чаралар оештыру һәм үткәрү.

3. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга инвалид балаларга белем бирүне дә кертеп, өстәмә белем бирүне үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү" ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре һәм субсидия бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына (алга таба – баш бүлүчегә) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә http://internet.garant.ru/document/redirect/22515068/0 бирелә.

4. Сайлап алуны үткәрү ысулы - аларга ирешү максатларында субсидия бирелә торган нәтиҗәләргә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып билгеләнә торган субсидия алучыны билгеләүдән гыйбарәт конкурс (алга таба - субсидия бирү нәтиҗәсе).

5. Коммерциягә карамаган оешмалар сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айдан алдагы айның 1көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара;

гамәлгә куючы (гамәлгә куючыларның берсе) белып Татарстан Республикасы тора;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган йөкләмәләргә ия түгел;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары юк;

үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаган, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән коммерциягә карамаган оешма җитәкчеләре, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки шәхси эшмәкәрнең баш хисапчылары (баш хисапчылар булганда) турында мәгълүматлар юк;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә https://internet.garant.ru/ - /document/12157576/entry/1000 тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр

юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормаса,

Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алучылар булып тормыйлар;

6. Субсидия турындагы мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

7. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән.

8. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешмалар баш бүлүчегә түбәндәге документларны тапшыралар:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерциягә карамаган оешма турында, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелә торган гариза, тиешле сайлап алуга бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыкны үз эченә алган гариза, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча исәп-хисаплар һәм чыгымнар нигезләмәләре белән керүче гаризаны;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып);

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар сметасы;

«Граждан Федераль салым хезмәтенең "Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын салым түләүче (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәү турында салым органы тарафыннан заявкаларны кабул итү срогы башланган көнгә кадәр айның беренче көненә бирелгән белешмә;

сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енә коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган, мөһер белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында акча йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаган, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге

Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган булуы турында коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган гарантияле хат;

коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер шәхси башкарма орган функцияләрен башкаручы затларга яисә оешманың баш хисапчысына (баш хисапчы булганда) Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрында булган белешмәләрне, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә формаларын һәм соратып алына торган мәгълүмат булмау турында белешмә бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтәләр һәм (яисә) соратылган мәгълүмат булмау турында белешмә;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның 2 һәм 4 пунктларында каралган коммерциягә карамаган оешмаларның заявкаларын сайлап алу критерийларына туры килүен раслый торган документлар.

Документлар коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә тапшырыла.

Кәгазьдә бирелгән барлык документлар да төгәл бастырып чыгарылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Гаризаның барлык битләре дә номерланган булырга тиеш. Гариза тегелгән һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган һәм гаризаның икенче ягында битләрнең гомуми санын күрсәтеп, мөһер (мөһер булган очракта) белән беркетелгән булырга тиеш.

Коммерциягә карамаган оешма әлеге пунктның бишенче һәм җиденче абзацларында каралган документларны тапшырмаган очракта, баш бүлүче күрсәтелгән документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Баш бүлүче сайлау үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда һәм үзенең рәсми сайтында сайлау үткәрү турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны үткәрү турында игъланда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү вакыты (гаризаларны бирү (кабул итү) башлану датасы һәм вакыты), алар сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң килүче 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш, шулай ук сайлап алу этапларын үткәрү мөмкинлеге турында мәгълүмат, аларны үткәрү срокларын (тәртибен) күрсәтеп (кирәк булганда);

баш бүлүченең исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почтасы адресы;

әлеге Тәртипнең 21 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итәлә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмаларга таләпләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан аларның күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан бирелә торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр һәм гаризалар бирү тәртибе;

гаризаларны кире алу тәртибен, гаризаларны кире кайтару (шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, гаризага үзгәрешләр кертү тәртибен;

гаризаларны карау һәм бәяләү кагыйдәләре;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны уздыру турында нигезләмәләргә аңлатма бирү тәртибен, шулай ук мондый бирүне башлау һәм тәгәлләү даталарын;

сайлап алуда җиңүче килешү имзаларга тиешле вакыт;

сайлап алу җиңүчесен килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый.

Гаризалар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән соң килүче календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә кабул ителә.

10. Гаризаны кабул иткәндә баш бүлүче аны кергән көнне сайлап алуда катнашуга гаризаларны исәпкә алу журналында терки һәм коммерциягә карамаган оешмага, аны алу датасын һәм тәртип санын күрсәтеп, гариза алу турында расписка бирә.

Сайлап алуда катнашуга бер генә гариза да бирелмәгән очракта, сайлап алу узмаган дип танылa.

11. Гариза аны теркәгән көннән алып ике эш көне эчендә баш бүлүче тарафыннан әлеге Тәртип таләпләренә туры килүгә тикшерелә. Баш бүлүче гаризаларны кабул итү тәмамланган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны гаризаларны карау комиссиясенә (алга таба - комиссия) җибәрә.

12. Гаризаны карау һәм бәяләү стадиясендә кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган гаризаларның һәм документларның сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән гаризаларга таләпләргә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән аның урнашкан урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

гаризаларны һәм документларны гаризалар кабул итү вакыты тәмамлану датасыннан һәм (яисә) вакытыннан соңрак тапшыру.

Гариза кире кагылган очракта, баш бүлүче гаризалар бирү срогы тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә коммерциягә карамаган оешмага бу хакта хәбәрнамә җибәрә.

13. Комиссия гаризаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң 14 календарь көн эчендә тапшырылган документларны карый һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итә. Сайлап алуны уздыру ачык тавыш бирү юлы белән комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла. Комиссия составы баш бүлүче тарафыннан раслана. Сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән гаризалар тапшырган яисә гаризалар тапшырган коммерциячел булмаган оешмалар штатында торучы), йә коммерциягә карамаган оешмаларга йогынты ясарга сәләтле затлар комиссия әгъзалары була алмый.

Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы була. Карар комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлары тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч тавыш булачак.

14. Гаризаларны караганда һәм бәяләгәндә комиссия әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә сайлап алу критерийлары нигезендә эш итә. Баллар баш бүлүче раслаган форма буенча тавыш бирү кәгазенә кертелә.

Субсидия гаризасы иң күп балл җыйган коммерциягә карамаган оешмага бирелә. Баллар саны тигез булганда, субсидия гаризасы элегрәк бирелгән коммерциягә карамаган оешмага бирелә.

15. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны комиссия сәркатибе алып бара. Беркетмә комиссия утырышын уздыру көнендә комиссия рәисе тарафыннан раслана.

16. Сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча баш бүлүче «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бердәм порталда һәм үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүматны урнаштыра: гаризаларны карау датасы, вакыты һәм урыны; гаризаларны бәяләү датасы, вакыты һәм урыны; коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат; гаризалары кире кагылган коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат, аларны кире кагу сәбәпләрен , шул исәптән мондый заявкаларга туры килми торган сайлап алу үткәрелү турында белдерүләр турында нигезләмәләрне күрсәтеп; гаризаларны бәяләү эзлеклелеге, гаризаларны бәяләү нәтиҗәләренә нигезләнеп кабул ителгән гаризаларны бәяләүнең һәр критерие буенча гаризалар бирү, гаризаларны тәртиптә номерлар бирү турында карар; килешү төзелә торган субсидияне алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме турында.

17. Комиссиянең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына коммерциячел булмаган оешма тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

18. Баш бүлүче:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып бер көн эчендә субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча килешү төзи.

19. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия күчерү графигы;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсе;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм рәвеше;

баш бүлүченең коммерциягә карамаган оешма тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм рәвешләрен билгеләү хокукы;

субсидияне (субсидия калдыкларын) кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидияләр калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, баш бүлүче тарафыннан аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә;

субсидия алучының, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның аларны тикшерүгә карата субсидия бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан аларны тикшерүгә ризалыгы;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алучы чит ил валютасы акчалары исәбеннән сатып алуны тыю;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, баш бүлүчегә моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

20. Субсидияләр күләме (С), шундый ук товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = С_1 + С_2,$$

монда:

$С_1$ – технопарклар базасында үткәрелә торган табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_1 = З_з + З_{р.м} + З_а + З_с + З_к + З_{п.о} + З_{и.к} + З_к + З_{о.к.о},$$

монда:

$З_з$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен исәпләүләр белән хезмәт өчен түләү фондына чыгымнар;

$З_{р.м}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен чыгым материалларын сатып алуга чыгымнар;

$З_а$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен урыннар арендалау буенча хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар;

$З_с$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен элемтә хезмәте күрсәтүләргә чыгымнар;

$З_к$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен хезмәт күрсәтүче оешмаларның (клинингның) хезмәт күрсәтүләренә чыгымнар;

$З_{п.о}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен оештыру техникасы һәм программа тәэминатын сатып алуга чыгымнар (банкларның хезмәт күрсәтүләренә чыгымнарны кертеп);

$З_{и.к}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат-консультация бирү буенча хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар;

$З_к$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен командировка, вәкиллек өчен сарыф итүләргә чыгымнар;

$З_{о.к.о}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен җиһазларның төп (мәҗбүри) комплектын сатып алуга, шул исәптән китереп бирүгә һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә чыгымнар;

$С_2$ – мобиль технопарклар базасында үткәрелә торган табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_2 = З_з + З_{тр1} + З_{тр2} + З_{р.м} + З_{пр},$$

монда:

$З_з$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен исәпләүләр белән хезмәт өчен түләү фондына чыгымнар;

$З_{тр1}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы ярышларда (чараларда) катнашу өчен транспорт хезмәте күрсәтүләргә, яшәү хезмәте күрсәтүләргә һәм тәүлеклек өчен чыгымнар;

$З_{тр2}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы белем бирү сессияләрендә һәм башка чараларда катнашу өчен

транспорт хезмәте күрсәтүләргә, яшәү хезмәте күрсәтүләргә һәм тәүлеклек өчен чыгымнар;

$З_{р.м}$ – табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны гамәлгә ашыру өчен чыгым материалларын сатып алуга чыгымнар;

$З_{пр}$ – арендага, коммуналь түләүләргә, ягулык-майлау материалларына, транспорт чарасына, җиһазларга һәм техникага хезмәт күрсәтүгә, транспорт чарасын иминләштерүгә, педагогик хезмәткәрләргә медицина тикшерүенә чыгымнар.

21. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган техник юнәлештәге өстәмә гомуми белем бирү программалары белән тәэмин ителгән 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар саны – кимендә 460;

балалар технопаркларының ачык чараларында катнашкан балалар саны – кимендә 1 312;

балалар технопаркларында эшләүче, ел саен өстәмә һөнәри программалар буенча белем алган педагогларның өлеше –кимендә 33 процент;

балалар технопаркларында белем алучы балалар тарафыннан башкарылган, проект эшчәнлеге нәтиҗәләрен тәкъдир итү буенча төбәк һәм федераль хисап чараларында тәкъдим ителгән проектлар саны – кимендә 19;

балаларның проект эшчәнлеге өчен реаль технологик бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән, гамәлгә кертелгән өстәмә гомуми белем бирү программалары саны – кимендә 7;

технопарклар базасында инженерлык проектларын даими нигездә гамәлгә ашыручы өч кешедән ким булмаган гомуми белем бирү оешмалрында укучылар төркемнәре саны – кимендә 13;

анда балалар технопаркларында белем алучы балалар катнашачак үткәрелгән инженерлык хакатоннары, инженерлык ярышларының төбәк этаплары, техник һәм табигый-фәнни юнәлештәге төп ярышлар һәм конкурс чаралары саны – кимендә 5;

балаларның проект эшчәнлеге буенча балалар технопарклары тарафыннан оештырылган ачык чаралар саны – кимендә 4;

мобиль технопарк программалары буенча белем алган балалар саны – кимендә 1 100;

мобиль технопарк инфраструктурасыннан файдаланып, «Технология» предмет өлкәсе буенча белем алучы төркемнәр саны, – кимендә 9;

мобиль технопарк инфраструктурасыннан файдаланып, табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә гомумүстерү программалары буенча белем алучы төркемнәр саны – кимендә 10;

мобиль технопарк катнашында үткәрелә торган чараларга җәлеп ителгән балалар саны – кимендә 3 200;

үткәрелгән массакүләм күргәзмәләр, мастер-класслар һәм башка активлыклар (Балаларны яклау көнен (1 июнь) һәм уку елы башлануны (августның соңгы атнасы) кертеп) саны, – кимендә 4.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

22. Баш бүлүче субсидияне, килешүдә билгеләнгән субсидияне күчерү графигы нигезендә, субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә:

агымдагы финанс елының I кварталы өчен – килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә;

агымдагы финанс елының II – IV кварталлары өчен – әлеге Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән, хисап кварталы өчен хисап бирелгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә.

23. Коммерциягә карамаган оешма субсидия алу һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтер исәбен алып бара.

24. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, баш бүлүче тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Баш бүлүче әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат коммерциягә карамаган оешмадан алынган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, коммерциягә карамаган оешманың агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калдык өлешен агымдагы финанс елына җибәрүгә ихтыяҗы булу яисә булмау турында бюджет законнары нигезендә карар кабул итә.

Агымдагы финанс елында коммерциягә карамаган оешмага ихтыяҗ булу турында төп боерык кабул ителгән очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше, баш бүлүче һәм коммерциягә карамаган оешма арасында, мондый карар кабул ителгән көннән башлап, календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көнлек өстәмә килешү төзелә.

25. Баш бүлүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, коммерциягә карамаган оешма финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы.

26. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче числосына кадәр, шулай ук хисап кварталыннан соң килүче елның 15 гыйнварына кадәр коммерциягә карамаган оешма баш бүлүчегә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, килешү рәвешендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән рәвешләр буенча бирелә.

27. Баш бүлүче һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

28. Субсидия баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә - субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән баш күрсәтмә бирүче һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракта;

тулы күләмдә - әлеге Тәртипнең 21 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгән очракта;

тулы күләмдә - субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта;

тулы күләмдә - субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирелмәгән очракта;

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә;

29. Татарстан Республикасы бюджеты керемено әлеге Тәртипнең 24 һәм 28 пунктларында күрсәтелгән очракларда иректе кире кайтарудан баш тарткан очракта, баш бүлүче, субсидия кире кайтару срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән жиде көн эчендә, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемено кайтару буенча чаралар күрә.

30. Субсидиянең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшерүдә тоту Россия Федерациясе законнары нигезендә баш бүлүче тарафыннан башкарыла.